**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2023 **Чирмешән авылы** **№ 147**

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында»**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар кылдым:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты;

- халык тыңлауларын үткәрү вакыты - 2023 елның 28 декабрендә 10.00 сәгатьтә.

- үткәрү урыны – түбәндәге адрес буенча урнашкан Кармыш авыл җирлегенең мәдәният йорты: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Кармыш авыл җирлеге, Кармыш авылы, Бари Габдрахманов урамы, 44А йорты.

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Кармыш авылы, Мәктәп урамы, 5 йорт, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү, ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркем төзергә түбәндәге составта:

Эшче төркем рәисе - Җамалетдинов Илнур Минсәгыйт улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Эшче төркем рәисе урынбасары - Вилданов Муса Габделхак улы, Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Эшче төркем әгъзалары:

Севастьянова Наталья Николаевна – Чирмешән муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Җиһаншина Эльвира Бурундай кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Гатина Рәмилә Рамил кызы - Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге башлыгы;

4. Әлеге карарны Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән 2023 елның 14 декабреннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга: https://cheremshan.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Чирмешән муниципаль**
**районы башлыгы** **Р.Т. Айбатов**